| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>СОВЕТ<br>БУИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Буа шәһәре

27 декабрь 2024 ел № 4-71

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының «2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты турында» 2023 елның 15 декабрендәге 1-56 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ**:**

1 статья

«2024 елга, 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советының 2023 елның 15 декабрендәге 1-56 номерлы карарына (2024 елның 29 мартындагы 8-59 номерлы, 2024 елның 19 июнендәге 2-61 номерлы,2024 елның 30 сентябрендәге 5-67 номерлы, 2024 елның 18 ноябрендәге 2-69 номерлы редакциядә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.** 1 статьяның 1 пунктындагы 1 пунктта «1 930 969,33» санын « 2 160 214,45» санына алмаштырырга, 2 пунктчада «1 967 003,84» санын «2 204 276,55» санына алмаштырырга, 3 пунктчада «36 034,51» санын «44 062,10» санына алмаштырырга.

2. 2024 елга 9 статьяда «1 328 250,43» саннарын «1 379 932,55» саннарына алмаштырырга.

3. 1 нче кушымтада «2024 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары» 1 нче таблицасын редакциягә әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә бәян итәргә.

4. 2 нче кушымтада «2024 елга Буа муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре» 1 нче таблицасын әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

5. 3 нче кушымтада «2024 елга Буа муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы» 1 нче таблицасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

6. 4 нче кушымтада «2024 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджеты ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары

классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлү» 1 нче таблицасын әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

7. 5 нче кушымтада «2024 елга Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлү» 1 нче таблицасын әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

8. 11 нче кушымтада «2024 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан алына торган бюджетара трансфертлар» 1 нче таблицасын әлеге карарга 11 нче кушымта нигезендә редакциядә бәян итәргә.

2 статья

Әлеге карарны Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталына урнаштырырга. pravo.tatarstan.ru.

3 статья

Әлеге карар басылып чыккан вакыттан үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Совет рәисе Р.Р.Камартдинов